| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**2025 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында**

Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы комиссиянең 2025 елда чыгарма тәртибендә дүрт Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләген тапшыру турындагы тәкъдимен караганнан соң, **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) составына Кашаев Айрат Рөстәм улы, Полубенцев Александр Михайлович, Гайфуллин Илнур Юрик улы кергән авторлар коллективына – «Иакинф» балетын сәхнәгә куйган өчен;

2) Гыйләҗев Мансур Аяз улына – «Словарь любви» («Мәхәббәт сүзлеге») пьесалар җыентыгы («Бичура», «Баскетболист», «Игезәкләр» һәм башка пьесалар) өчен;

3) Шәрипов Рәнифкә – «Җомга», «Бөртек-бөртек яктылык» китаплары өчен;

4) Якупов Рифхәт Госман улына – Татарстан Республикасында фотография сәнгатен үстерүгә, татар халкының мәдәни мирасын саклауга зур өлеш кертүе һәм «Сабантуй» фотоальбомы өчен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ · АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 26 апрель
№ 326